**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш
**КАРАРЫ**

24.01.2023 ел №2 Урыссу ш.т.п.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 17.03.2020 ел, № 17 Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында 17.03.2020 ел, №17 карары белән расланган карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында” 22.12.2022 ел, № 121 Карары, «Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында 17.03.2020 ел, №17 карарына үзгәрешләр кертү турында” Карары проекты буенча гавами тыңлауларның 23.01.2023 ел №1 беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 17.03.2020 ел, № 17 Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" 17.03.2020 ел, № 17 Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар карар кабул итә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында 17.03.2020 ел, №17 Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьяның IX өлеше III бүлеге «Ж1 - шәхси торак төзелеше зонасы» 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**1. «Ж1 - Шәхси торак төзелеше зонасы**

1.1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары:

| **Рөхсәт ителгән куллану төре коды *** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре исеме *** | **Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең һәм реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **җир кишәрлеге зурлыгы** | **катларның чик саны һәм төзелешнең чик биеклеге** | **максималь төзелеш проценты** | **җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр** |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре** | | | | | |
| 2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен | минималь - 1000 кв. м; максималь - 2000 кв.м. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (авыш түбәле, "конек"та биеклек). Ихаталарның максималь биеклеге - 2,0 м. | 20 % | урам-юл челтәренә чыгучы җир кишәрлеге яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен - билгеләнми. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенүне киметү яки кызыл линия буенча биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 2.2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге) | минималь - 2000 кв. м; максималь - 5000 кв.м. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче | 20 % | урам-юл челтәренә чыгучы җир кишәрлеге яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (авыш түбәле, "конек"та биеклек). Ихаталарның максималь биеклеге - 2,0 м. | | өчен - билгеләнми. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенүне киметү яки кызыл линия буенча биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 2.3 | Блокланган торак төзелеше | минималь - 1000 кв. м; максималь - 2000 кв.м. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (авыш түбәле, "конек"та биеклек). Ихаталарның максималь биеклеге - 2,0 м. | 30 % | урам-юл челтәренә чыгучы җир кишәрлеге яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен - билгеләнми. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенүне киметү яки кызыл линия буенча биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 2.7.1 | Автотранспортны саклау | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.9.2 | Транспорт чараларының тукталу урыны | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** | | | | | |
| 2.7 | Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 12.0 | Гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр) | билгеләнми | | | |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.1 | Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше | минималь - 400 кв. м.; максималь - билгеләнми | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 4 (мансардны да кертеп); Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 15 м; Ихатаның максималь биеклеге - 1 м. | 40 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенүне киметү яки кызыл линия буенча биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 4.9.1.3 | Автомобиль юу урыннары | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 4.9.1.4 | Автомобильләрне ремонтлау | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 13.1 | Бакчачылык алып бару | минималь - 600 кв. м.; максималь - 5000 кв.м. | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |

*РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә

1.2. Башка таләпләр:
Минималь аралар:
2 - 3 кат биеклектәге торак биналарның озын яклары арасында: кимендә 15 м;
4 катлы биеклектәге озын яклары арасында: кимендә 20 м;
балалар уеннары өчен мәйданчыктан алып торак биналарга кадәр - 12 м;
өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыгыннан - 10 м;
автомобиль кую мәйданчыкларыннан - 10 м;
спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыктан - 10 метрдан 40 метрга кадәр ;
хуҗалык максатлары өчен мәйданчыктан - 20 м;
калдыклар өчен контейнерлар булган мәйданчыклардан алып торак йортлар, балалар учреждениеләре участоклары чикләренә, яшелләндерелгән мәйданчыкларга кадәр - кимендә 50 м, әмма 100 метрдан артык түгел.

Автомобиль транспортын саклау урыннарыннан тыш, урамнар ягыннан ярдәмче корылмаларны урнаштыру рөхсәт ителми.

Социаль, коммуналь-көнкүреш, административ һәм башка билгеләнештәге объектлар торак йортларның аскы ике катында урнаша ала, яки, аларга якын урнашырга мөмкин, әгәр алар торак (ишегалды) территориясеннән аерымланган булса, автотранспортка вакытлыча тору өчен кунак ачык автостоянкалары өчен мәйданчыклар, керү урыннары булган очракта.

Әлеге статьяда җайга салынмаган күрсәткечләр техник регламентлар, норматив техник документлар, шәһәр төзелешен проектлау нормативлары һәм башка норматив документлар таләпләре нигезендә билгеләнә.

Шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән җир кишәрлекләренең чик (минималь) күләмнәре түбәндәге очракларда кулланылмый:

- шәхси милектә булган җир кишәрлеген һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән җир участогы барлыкка килү, мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләмнәренә туры килгән җир участогын формалаштыру мөмкинлеге булмау;

- дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) булганда һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмаганда;

- ике һәм аннан күбрәк җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге барлыкка китерү;

- гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин.